**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 13 март № 151

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 ел, 28 декабрь, ФЗ-442 нче Федераль законны тормышка ашыру кысаларында кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокук актларын камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән, әмма дәүләт йөкләмәсен (заказын) үтәүдә катнашмый торган социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 25 ноябрь, 906 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 23 гыйнвар, 34 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән, әмма дәүләт йөкләмәсен (заказын) үтәүдә катнашмый торган социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләү тәртибенең 7 нче пунктындагы 6 нчы пунктчасы үз көчен югалткан дип санарга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәт күрсәтүләрнең индивидуаль программасын төзү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 25 ноябрь, 908 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәт күрсәтүләрнең индивидуаль программасын төзү тәртибендә:

4 нче пункттагы «Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кадрлар әзерләү һәм тармакны үстерү комплекслы үзәге (алга таба – Комплекслы үзәк)» дәүләт казна

учреждениесе» сүзләрен «Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы әлеге функцияләр йөкләнгән дәүләт казна учреждениесе (алга таба – Учреждение)» сүзләренә алыштырырга;

8, 10 – 12, 17 нче һәм 19 нчы пунктлардагы тиешле килешләрдәге «Комплекслы үзәк» сүзләрен тиешле килешләрдәге «Учреждение» сүзенә алыштырырга;

11 нче пункттагы «социаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргән гражданга җавап рәвешендә» сүзләрен «Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы раслаган форма буенча» сүзләренә алыштырырга;

11 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтү турында карар «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 ел, 28 декабрь, ФЗ-442 нче Федераль законның 21 статьясында каралган тәртиптә ашыгыч рәвештә кабул ителә»;

13 нче пунктның бишенче абзацындагы «һәм Татарстан Республикасының» сүзләрен төшереп калдырырга;

19 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Индивидуаль программа ике нөсхәдә төзелә. Индивидуаль программаның Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе кул куйган нөсхәсе граждан социаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган иң күбе ун эш көне эчендә гражданга яки аның законлы вәкиленә тапшырыла. Индивидуаль программаның икенче нөсхәсе Министрлыкның территориаль органында кала.»;

22 – 24 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22. Учреждение белгече, гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турындагы карарга Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе кул куйган көннән өч эш көне үткәнгә кадәр, әмма граждан социаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргән көннән иң күбе сигез эш көне эчендә индивиуаль программа проекты әзерләнә һәм карап тикшерү һәм кул кую өчен Министрлыкның территориаль органына җибәрелә.

23. Министрлыкның территориаль органында бер эш көне эчендә индивидуаль программа проектын карап тикшерү, аңа кул кую һәм гражданга (аның законлы вәкиленә) бирүне оештыру өчен Учреждениегә җибәрү гамәлгә ашырыла.

24. Граждан яки аның законлы вәкиле социаль хезмәт күрсәтүдән, социаль хезмәтләрдән баш тартырга хокуклы. Баш тарту турындагы карар язма рәвештә рәсмиләштерелә, һәм тиешле мәгълүмат индивидуаль программага кертелә.»;

түбәндәге эчтәлекле 26 нчы пункт өстәргә:

«26. Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучының яшәү урыны үзгәргән очракта, Россия Федерациясенең башка субъектында элек яшәгән урыны буенча төзелгән индивидуаль программа бу Тәртип нигезендә яңа яшәү урыны буенча индивидуаль программа төзелгәнгә кадәр Татарстан Республикасында билгеләнгән социаль хезмәтләр күрсәтү исемлеге күләмендә үзенең гамәлен саклый.».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләмен һәм аны алу тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 ноябрь, 927 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пункттагы «(социаль хезмәт күрсәтелгән 30 көн өчен)» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасы нигезендә социаль хезмәтләр күрсәткән өчен түләү алу тәртибенең 4 нче пунктында:

беренче абзацтагы «социаль хезмәтләр күрсәткән өчен түләү» сүзләре алдына «Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар һәм ярымстационар формаларында» сүзләрен өстәргә;

икенче абзацтагы «арттырып түләнгән сумма киләсе ай өчен кертеләчәк түләүгә исәпләнә йә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче билгеләгән тәртиптә социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыга кире кайтарыла» сүзләрен «түләнгән, ләкин күрсәтелмәгән хезмәтләр кыйммәте күләмендәге акча киләсе ай өчен кертеләчәк түләүгә исәпләнә йә социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыга биш эш көне эчендә кире кайтарыла» сүзләренә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\151.doc